РУХЫБЫЗ САУМЫ?

Белгечләр республикада үз-үзенә кул салучылар саны артуга борчыла

> 2

УКУЧЫ СҮЗЕ

«ВТ» укучылары хатларында – тормыш кыйпылчыклары

> 3

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

Әти-әниләре бөтен гомерен, бөтен сәламәтлеген аларга багышлый, ә балалары җавапсыз кала

> 4

ЛИЛИЯ МӘХМҮТОВА:

«Күңел» елдан-ел яшәрә»

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 146 (28919) | Чәршәмбе | 5 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

КИЛӘЧӘК НИГЕЗЕ

ПРЕЗИДЕНТ КРЕМЛЬДӘ МӨГАЛЛИМНӘРНЕ КОТЛАДЫ

Укытучы булып туарга кирәк! Казан Кремлендә дәүләт бүләкләренә ия булган мөгаллимнәрнең күбесе әнә шулай диде. Халыкара укытучылар көне уңаеннан гомерен әлеге хезмәткә багышлап, уңышка ирешкән укытучыларга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов дәүләт бүләкләрен тапшырды.

– Укытучы – иң дәрәҗәле һөнәрләренең берсе. Үзләренең шәхси үрнәгендә алар киләчәккә нигез сала, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Илебезнең киләчәге: иртәгә оешма, хастаханә, балалар бакчасы, мәктәпләргә кемнәр киләсе дә, илне кемнәр яклыйсы да нәкъ менә сезгә бәйле. Бүген залда «алтын фонд»ыбыз – халык укытучылары, педагогик династия вәкилләре. Сезнең алга таба да үз һөнәрегезнең данлы традицияләрен саклавыгызга ышанам. Барыгызны да бәйрәм белән котлыйм.

Президент әйткәнчә, мәктәпләрдә үз фәненә мәхәббәт уяткан, яхшы белем биргән укытучылар күп. Моны нәтиҗәләр күрсәтә. Узган уку елында 237 укучы бөтенроссия олимпиадалары призеры һәм җиңүчесе булган. Өч укучы математика һәм химиядән халыкара олимпиадада җиңү яулаган. 2 меңнән артык укучы мәктәпне медальгә тәмамлаган. Президент күптән түгел һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үткән һөнәри уку йортларында белем бирүче педагогларны да котлады.

Укытучыларның йөзләрендә үк зыялылык чагыла. Татарстан Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире Рәсимә Шәмсетдинова – укытучыларның остазы. Чарада аңа «Татарстанның халык укытучысы» исеме бирелде. Хезмәт юлын 1975 елда ук башлаган укытучы бу бүләкне көткәнме?

– Укытучыларның берсе дә хезмәтен дәрәҗә турында уйлап башламый торгандыр. Киресенчә, курку, дулкынлану белән башлый. Бигрәк тә минем очракта бу шулай. Университетны тәмамлагач, Казан педагогия училищесына укытырга киттем. Искиткеч педагоглардан торган коллектив иде ул. Шулар арасына килеп керү миңа җаваплылык та өстәгәндер. Хезмәттәшләремә гомер буе рәхмәтлемен, нәкъ менә алар миннән укытучы ясады, – дип искә алды ул беренче эш көннәрен.

Бүген яшь укытучыларның мәктәптән китүенең бер сәбәбе – әти-әниләр белән уртак тел таба алмау. Ышанасызмы, Казандагы 170 нче мәктәпнең математика укытучысы Ләйлә Гыйләлетдинованың үз гомерендә беркайчан да алар белән бәхәскә кергәне, ызгышканы булмаган. Хезмәт стажы да кечкенә түгел – 42 ел!

– Әллә миңа гына шундый яхшы әти-әниләр туры киләме – белмим. Без бик тату яшибез. Узган уку елында 11 нче сыйныф укучыларын чыгардым. Быелгы уку елында 5 нче сыйныфларны бирделәр. Алар белән дә яхшы эшлибез. Балалар үзгәрә, үзебез дә шуларга карап үзгәрәбез. Заман таләпләренә җавап бирергә тырышабыз, – ди йөзеннән иплелек бөркелгән мөгаллимә.

Балык Бистәсе районыннан килгән Закировлар – Урматовлар гаиләсенең хезмәт стажы 700 елдан артык.

Әлки районының Югары Әлморза мәктәбендә кулибиннар тәрбияләүче Марс Нотфуллин турында газетабыз битләрендә еш язып торабыз. Бәйрәмдә ул «Татарстанның атказанган укытучысы» исеменә лаек булды.

– Бу көннәрдә 55 яшь тулды миңа. Шуның 33 елын мәктәптә эшлим. Балалар белән дәрестән тыш, трактор, автомобилен дә, катамаранын да ясыйбыз. Аларга тиз булсын. Кайчан озаккарак сузылса, эшләнеп бетмәгән килеш тә кабызып карыйсылар килә, – ди Марс Нотфуллин. – Башта укытучы буласы килмәде минем. Колхоз кырларында тракторчылар җитмәгәч, аларны өйрәтергә техник-механикка укыган идем. Аннан инде халыкка белем бирү авыррак икәнен аңлап, мәктәпкә килдем. Үземнең беренче укытучы Гөлфирә Абдулловна мәктәпкә эшкә чакырган иде. Аңа бик теләп рәхмәт әйтәсем килә дә бит, тик ул мәрхүмә инде.

Балык Бистәсе районыннан килгән Закировлар – Урматовлар гаиләсенең хезмәт стажы 700 елдан артык. Әлегә нәселдә укытучылар саны 30га җиткән. Бәйрәмгә алар арасыннан өч укытучы килгән иде. Алар 100 мең сумлык сертификат белән бүләкләнде.

Рафыйк Закиров – Мәшләк мәктәбе директоры. Аның тормыш иптәше Ләйсән Закирова Котлы Бөкәш мәктәбендә башлангыч сыйныфларны укыта.

– Укытучы эше йокларга ятканчыга кадәр бетми. Төштә дә балаларны күрәбез, – ди Ләйсән Закирова. – Әти-әниләрем укытучы булгач, аларга дәфтәр тикшерергә булыштык. Апалар – укытучы, ике кызыбыз да безнең юлдан китте. Бармагыз, дисәк тә, бардылар. Бу безнең канга сеңгән.

Тантанадан соң Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллинның да фикерләрен белештек.

– Бу – бик зур бәйрәм. Укытучыларны ай гына түгел, ел буе котласаң да, бик аз әле. Укытучы – илаһи бер зат. Аңа бүген һәйкәл куярга вакыт җитте. Шундый һәйкәл булса, һәрбер бала, әти-әни шунда килеп, башын иеп китәр иде, чөнки һәрберебезнең укытучысы бар. Укый-яза белмәгән сабыйлар булып мәктәпкә килеп, белем алып чыккан кешеләр без, – диде министр.

Министр белдергәнчә, хәзерге укытучы заман таләпләренә туры килә. Яшьләрне яшьләрчә тәрбиялиләр, өлкәннәргә өлкәннәрчә карыйлар.

Ахыры 2 нче биттә >

Гаризалар кабул итеЛӘ

Россиядә өлешчә мобилизация игълан ителгән көннән башлап Дәүләт хезмәтләре порталында махсус хәрби операциядә катнашырга теләк белдерүчеләрдән 70 меңләп гариза теркәлгән. Бу хакта «ТАСС» мәгълүмат агентлыгы хәбәр итә. Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко сүзләренә караганда, узган елларда гына да ике меңләп кеше гариза биргән. «Махсус хәрби операциядә катнашырга теләк белдереп гариза тутыручыларга ике көн эчендә документлар исемлеге белән бергә хәрби комиссариатка чакыру киләчәк», – дигән ул.

Моннан тыш, хәзер Дәүләт хезмәтләре порталында мобилизациягә чакырылучылар шикаять тә белдерә ала. Бу хәрби хезмәткә баруны кичектереп тору өчен сәбәбе, ягъни отсрочкасы була торып та, мобилизациягә эләгүчеләр өчен эшләнгән. Шикаятьне мобилизациягә эләгүче дә, аның якыннары да бирә ала.

Бу атнада тәмамлана

Россия Дәүләт Думасында ил составына кергән яңа субъектларның статусын рәсмиләштерү эше кайчан төгәлләнәчәге турында аңлаттылар. Искәртеп үтик: Россия Президенты Владимир Путин 30 сентябрьдә ил составына яңа дүрт төбәкне кушу турында шартнамәгә кул куйды. Болар – Луганск һәм Донецк халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләре.

Яңа төбәкләргә конституцион статус бирү процедурасы берничә көн дәвам итеп, бу атнада тәмамланыр дип көтелә.

«Хәзер Федерация Советы федераль конституцион законнарны хупларга, ә аннан соң шуларны ил Президенты имзаларга тиеш», – дип аңлатты Дәүләт Думасы депутаты Константин Бахарев. Россия Президенты кул куйганнан соң, документлар басылып чыгачак һәм үз көченә керәчәк.

Онытылганны кайтарганнар

Ел башыннан Казанның җәмәгать транспорты йөртүчеләре автобусларда табылган 500дән артык әйберне ияләренә кайтарган. Транспортта әйберләрен онытып калдыручыларның иң күбе мәктәп укучылары, студент һәм пенсионерларга туры килә икән. Транспортта күпчелек банк картасы, букча, балалар киеме, алмаш аяк киеме, зонт, фатир ачкычы, телефоннар табыла.

Әгәр пассажирлар үз әйберләрен автобуста оныткан булса, аларга автобус маршрутына хезмәт күрсәтә торган автотранспорт предприятиесенең диспетчерына кичекмәстән шалтыратырга кирәк, дип хәбәр итә Татарстанның автотранспорт предприятиеләре ассоциациясе.

Сак булыгыз!

Татарстанда талпан кадалудан зыян күрүчеләр саны 62,2 процентка арткан. Медицина оешмаларына шул сәбәп белән барлыгы 9,2 мең кеше мөрәҗәгать иткән. Мөрәҗәгатьләрнең иң күбе – Казан (2569) һәм Чаллыда (1490).

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе матбугат хезмәте искәрткәнчә, талпаннарның активлык чоры апрель һәм октябрь айларына туры килә. Талпан кадалганда аны алу, вируслы энцефалитны профилактикалау өчен, кичекмәстән медицина оешмасына мөрәҗәгать итәргә кирәк, ди белгечләр.

Яшәеш

Күңел картаймый

Республикада яшәүче һәр дүртенче кеше пенсия яшендә. Әби-бабайларның күп өлеше авылда яши. Анда һәр өченче кеше өлкән яшьтә. Бу хакта Министрлар Кабинетында узган очрашуда сөйләделәр.

Татарстанда 1 сентябрьгә булган мәгълүматларга караганда 100 яшьтән узган 140 хатын-кыз һәм 17 ир-ат бар. Өлкәннәр – игътибар үзәгендә. Аларга тиешле түләүләр дә вакытында бирелеп барыла.

– Татарстанда төрле оешмаларда эшләүче пенсия яшенә җитеп килүче 250 меңнән артык кеше бар. Алар әле пенсиягә чыкмаган булсалар да, кайбер ташламалардан файдаланалар, – ди Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова. – Андыйларны дәүләт ярдәме белән укытабыз да. Әгәр кешегә эшсез калу куркынычы бар икән, яки ул эшләгән оешмада башка төрле һөнәр ияләре кирәк икән, бушлай укытулар оештырыла. Бу хакта үзегез яшәгән районның эш белән тәэмин итү үзәкләре аша белә аласыз.

Эльмира Зарипова «Демография» илкүләм проекты кысасында тормышка ашырылучы программаларга да тукталды. Авылларда яшәүче пенсия яшендәге өлкәннәрне хастаханәләргә тикшерену үтәр өчен бушлай йөртү, авыру якыннарын караучыларга сиделка ярдәме оештыру, кайбер кешеләрне өлкәннәрне тәрбияләргә өйрәтү өчен махсус укыту кебек кирәкле эшләрне аңлатып сөйләде. Быел 301 өлкән яшьтәге кешегә сиделка хезмәте күрсәтелгән, 2 меңнән артык кеше авыруларны карарга өйрәнгән. Тернәкләндерү үзәкләрендә 940 кеше сәламәтлеген ныгыткан.

Сәламәтлек дигәннән, бу хакта Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Альмир Абашев сөйләде. Ул өлкәннәр өчен ачылган гериатрия кабинетларына тукталды. Республиканың һәр районында мондый бүлмәләр бар икән. Бүген 65 кабинет эшли, хастаханәләрдә олылар өчен 175 урын булдырылган. Республикада 135 табиб-гериатр эшли. «Әлеге табиблар – өлкәннәрнең сәламәтлеген кайгыртып, аларга ярдәм итеп, гомер озынлыгын арттыручылар, – ди Альмир Абашев. – Соңгы вакытта 80 яшьтән узган күп кенә өлкәннәрнең бот сөяге сына. Алар янәшәсендәге кешеләр игътибарлы булсын иде. Бот сөяге сынган кешегә 48 сәгать эчендә генә ярдәм итеп була. Әгәр вакытында операция ясамасаң, өлкәннәр үлеп тә китәргә мөмкин».

Очрашуда өлкәннәрнең компьютер осталыгына өйрәнүләрен дә сөйләделәр. Баксаң, күбесе инде смартфоннарда да оста гына интернетка керә белә, үзенә кирәк мәгълүматны таба икән. Финанс грамоталылыгына да, компьютерга да «Өченче буын» университетында өйрәтәләр.

Ә менә пенсия мәсьәләләре буенча сораулар булса, 8-800-6000000 телефон номерына шалтыратырга була. Россия Пенсия фондының Татарстан буенча идарәчесе Эдуард Вафин әйтүенчә, нинди генә сораулар туса да, шушы номерга шалтыратырга була. Аның сүзләренчә, республикада картлык буенча түләнә торган пенсиянең күләме 19 мең сум тәшкил итә.

– Эшләүче пенсионерларның исә пенсияләре, алар эштән китеп бер ай узгач, индексацияләнә. Өстәмә акча өч ай эчендә түләнә. Эштән киткән кеше, пенсия күләме үзгәргәч, яңадан эшен дәвам иттерә ала. Бу очракта пенсия күләме шул килеш саклана, – ди ул. – Республикада 80 яшьтән узган 137 меңнән артык кеше яши. Әмма аларның күбесе үзләренә тиешле 1200 сум өстәмә акчаны алмый. Моның өчен 14 яшьтән узган, беркайда да эшләмәүче кешене үзеңнең караучың итеп билгеләргә кирәк. Шуннан соң акча сезнең пенсиягезгә өстәлеп киләчәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сүзгә-сүз

Лилия ГОМӘРОВА, Федерация Советының Фән, мәгариф һәм мәдәният комитеты рәисе:

Россиядә мәктәпләрне террорчылыкка каршы җиһазлауның бердәм федераль программасын булдырырга кирәк. Ул илебез предприятиеләрендә бердәм стандартлар буенча мәктәпләр куркынычсызлыгы өчен кирәкле җиһазлар эшләп чыгару таләбен дә үз эченә алырга тиеш. Безнең сәнәгать металл кысаларны да, видеокүзәтү системаларын да эшли ала. Бу, беренчедән, бюджет акчасын янга калдырачак, икенчедән, мәктәпләрне бөтен җирдә дә бер үк төрле җиһазларга мөмкинлек бирәчәк.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – УРМАННАР

«Меркатор» компаниясе Россия урманнары турында кызыклы белешмә әзерләгән.

Россия гомуми территориясенең ***52 проценты*** *урманнар белән капланган.*

Якутия	167 млн га
Красноярск крае	124 млн га
Иркутск өлкәсе	66 млн га
Хабаровск крае	60 млн га
Байкал аръягы крае	31 млн га

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 3–13 октябрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны

Ташламалы бәя 444 сум 54 тиен

гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга

Ташламалы бәя 980 сум 10 тиен

гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ДОМИНО КАЙЧАН ИШЕЛЕР?

Дүшәмбе базарларга берничә яңалык алып килде. Беренчесе: ОПЕК+ нефть чыгаруны көнгә бер миллион баррельгә киметергә җыена. Искә төшерик әле: андый масштаблы киметүләр кайчан була иде? Зур кризис киң итеп җәелгәндә. Дөньякүләм масштаблы катастрофа булганда. Әйтик, коронавирус пандемиясе игълан ителгән 2020 елның мартында «кара алтын» шулкадәр бәясен югалтты: эшкәртүчеләр нефть чыгаручыларга, акча түләсәгез генә чималыгызны алабыз, дип янадылар. Җир мае шулкадәр очсызлангач, ОПЕК+ җыелды да тиңе булмаган киметү игълан итте. 2008, 2015 елгы кризисларда шулай ук җир маен чыгаруны миллион сигез йөз мең баррель тирәсе киметтеләр. Андый адымнар нефть бәясен югарыга күтәреп тотрыкландырырга булыша. Аз сатасың, әмма табыш кимеми. Бәя кискенрәк күтәрелсә, арта да әле. Картель шушы традицияне кабатларга җыена. Нәрсә булды соң? Табигый бәла-казалар да күренми. Пандемияне, Аллага шөкер, оныттык, курыкмыйбыз. Чирләсәк тә, ис китми.

Икенче вариант кына кала: зур кризис килә. Авторның берәүне дә куркытасы килми, әмма моңарчы күрелмәгән бөек кризис ишек шакый. Ул хәтта үткән гасырның утызынчы елларындагы Бөек депрессиядән дә хәтәррәк булачак. Аның киләчәге хакында без күптән язабыз бит инде. Математик исәп белән аны 2022–2023 елларда башланыр дип гел әйтә килдек. Хәзер офыкта шул кризисның аҗаганы уйный, беренче яшеннәре көтелә. Европада берьюлы зур өч банк түнтәрелеш алдында тора. Швейцария банкы Credit Suisseның мәтәлчеге башланачагы хакында кичә язган идек. Фаразны дөресләп, дүшәмбе сәүдәсендә Credit Suisse 12 процентка очсызланды. Банкка ияреп, швейцар франкы да кыйммәтен югалтты. Сезнең анда акчагыз юкмы? Булмаса да тынычланмагыз, чөнки түнтәрелеш озакламый безнең фәкыйрь кесәләргә дә сугачак. Deutsche Bank – немецларның зур банкларыннан берсе – шулай ук авыр хәлдә. Швейцар партнерлары ишелсә, аларга иярми калмас. Безнең «Ак Барс» банкы, чит илгә акча күчергәндә, Deutsche Bank аша эш йөртә иде дип беләм (сүз уңаеннан, авторның «Ак Барс» банкы хисабында 2 фунт стерлингы янып ята). Француз банкы Societe Generale – банкротлык алдында. Боларның упкынга очуына айлар түгел, санаулы көннәр генә калды, диләр. Европа банклары ишелү домино эффекты бирәчәк. Америкада да, Азиядә дә зур финанс мәтәлчеге башланачак. Кытайның Үзәк банкы эре дәүләт банкларына долларларны сатарга әзер торырга кушты. Чиннар белә нинди афәт якынлашканны. Үз банкларының да хәлләре яхшы түгел, илнең дәүләт әҗәте коточкыч суммада. 16 октябрьдә Кытай компартиясе съезды көтелә. Пекин, шул съезд узганчы, хәлне тотрыклы сакларга тели.

Берләшкән Милләтләр Оешмасында да алда көтелә торган финанс давылыннан куркалар. БМО АКШның Федераль резерв системасын һәм башка илләрнең Үзәк банкларын процент ставкасын күтәрүне туктатырга чакырды. Үзәк банклар процент ставкасын күтәреп, дөнья икътисадын рецессиягә этәрләр, дип әйтәселәре килә БМОдагыларның. Ярый хуш, банкирлар дипломатларны тыңладылар, ди. Шуннан нәрсә? Гиперинфляция көтелә ул чакта. Ул шулай ук рецессиягә китерәчәк. Пат вазгыятеннән чыгарга юл юк.

Россиядә

РОССИЯ: КОЛЛПАС КӨТЕЛӘМЕ, ЮКМЫ?

Дүшәмбе көнне Америка икътисадчысы, кризисларны фаразларга яратучы философ, чыгышы белән япон булган шәхес, «Тарихның бетүе һәм соңгы кеше» дигән атаклы китапның авторы Фрэнсис Фукуяма: «Якындагы көннәрдә Россиядә зур коллапс булачак», – дип белдерде. «Ватаным Татарстан» хәбәрчесе Фукуяманың бу фикеренә кушылырга җыенмый. Кире дә какмый, билгеле. Бар дөньядагы шикелле үк бездә дә хәлләр авыр, әлбәттә. Энергия чыганаклары өстендә утыруыбыз безнең хәлне бераз җиңеләйтә. Һәм… авырайта да. Дәүләт идарәсе механизмы эштән чыгып ватылса, бернинди табигый байлыклар да коткармаячак. Мобилизация шаукымы башлангач, барыбыз дә күрдек: төгәл сәгать кебек эшләргә тиешле хәрби комиссариатлар системасы ватык телефон кебек кылана. Югыйсә, өлешчә мобилизация турында игълан иткәндә, Путин да, Шойгу да хәрби хәрәкәтләргә кемнәр чакырылырга тиешлеген ачык итеп әйттеләр. Алар әйтмәсә дә, хәрби комиссарларның үз башлары эшләргә тиеш иде. Чакыру шундый итеп башланды: тавышы Путинга барып җитте һәм лидер хәрби җитәкчелекне тәнкыйтьләп чыгыш ясарга мәҗбүр булды. Алтмыш һәм аннан өлкәнрәк яшьтәгеләрнең мобилизацияләнүе шаккатыргыч гаҗәп инде. Медицина комиссиясеннән башка да боларда бер бәйләм хроник чир барлыгын, яшьләре сәбәпле, физик мөмкинлекләре чикләнгән булуын аңларга әллә ни акыл кирәкми. Әйе, алар кире кайтарылдылар. Тиешсез чакырылган башка ирләр дә нигездә гаиләләренә кайтты. Кайбер өлкәләрдә хәрби комиссарлар алышынды. Әмма бездә дәүләт аппаратының үтә начар эшләве тагын бер тапкыр расланды. Шулай булгач, Фукуяма фаразы тормышка ашса, бер дә гаҗәп түгел.

Без яшәгән илнең керемнәре, кайбер белгечләр әйтүенчә, 75–95 процентка кадәр углеводородлар сатудан килә. Кайбер белгечләр, хәзер алар үткән елгының 25 процентын гына тәшкил итә, диләр. Бу әле нефть һәм газга бәяләр гадәттән тыш югары торганда шулай. Дөнья кризисы ул бәяләрне түбәнгә ыргытачак. Чималдан башка нәрсәдер җитештерергә без әле өйрәнмәдек. Идарә аппараты хәзерге хәлдә булганда өйрәнә дә алмабыз, мөгаен.

Менә бу кризиска Татарстан берникадәр әзерлекле һәм яхшырак позициядә керә. Россия төбәкләре җитештерүне киметкән, финанс хәлләрен начарайткан вакытта, бездә Идел буе федераль округына кергән төбәкләр арасында сәнәгать җитештерүе индексы иң яхшысы. Быелның гыйнвар – август күрсәткечләре үткән елның шул чоры белән чагыштырганда үргә таба күтәрелүне раслый. Сәнәгать җитештерүе индексы – 109,3 процент. Бу 2022 елда дөнья күләмендә иң нык үсешкә ирешкән Согуд Гарәбстаны нәтиҗәләре кебек диярлек. Шулай булгач, иң авыр чорны без җиңелрәк узмабызмы дигән өмет чаткысы бар.

КЕЧКЕНӘ АВЫЛЛАРНЫҢ ЗУР СӨЕНЕЧЕ

Быел яңа уку елын Кукмара районы Балыклы авылының башлангыч сыйныф укучылары матур, яңа бинада башлаган. Кукмара районының мәгариф идарәсе башлыгы Илфат Әхмәдуллин әйтүенчә, авыл Олыяз авыл җирлегенә керә.

tatarstan.ru

Кукмара районының Балыклы авылында 15 бала белем ала.

– Олыяз авылындагы урта мәктәпкә 160 укучы йөри. Ә Балыклы авылындагы филиал мәктәптә 15 бала белем ала, – диде ул. – Балалар моңа кадәр шушы белем йортында укыды, тик анда барлык шартлар да юк иде. Туклану блогы белән дә авырлыклар бар иде. Нәтиҗәдә, без бинаны тулысы белән сүтеп, яңа мәктәпне сафка бастырдык. Бу 47 млн сумга төште.

Әлеге мәктәпне төзү «Авыл территорияләрен комплексы үстерү» федераль программасы нигезендә тормышка ашырылган. Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Марсель Мәхмүтов китергән мәгълүматлар буенча, 2019–2022 елларда моның өчен 9,6 млрд сум акча тотылган. Быел исә республикада әлеге программа өчен 1,7 млрд сум каралган. Билгеле булганча, программа авыл халкының торак шартларын яхшыртуга, аларны социаль-мәдәни, көнкүреш һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

– Кечкенә авыллардагы аз санлы балалар укый торган башлангыч мәктәпне төзекләндерү, күпфункцияле комплекслар салу өчен бик яхшы программа бу, яшьләрне авылга кайтаруның бер ысулы. Мәктәбе, балалар бакчасы бар икән, яшь гаиләләр дә төпләнеп калыр иде. Шуңа күрә без ничек тә кечкенә авылларны шушы объектлар белән тәэмин итәргә тырышабыз, – диде Илфат Әхмәдуллин.

Гомумән алганда, әлеге программада Кукмара, Саба районнары – лидерлар. Быел соңгысында да 500 укучыга исәпләнгән мәктәп ачылган. Киләсе елга да кукмаралыларның планнары зурдан. Чура авылындагы төп мәктәпне капиталь төзекләндермәкчеләр икән. Шушы ук җирлеккә караган Поршур авылында күпфункцияле үзәк ачарга ниятлиләр. Биредә 15 укучыга исәпләнгән башлангыч мәктәп тә, 15 бала йөреячәк балалар бакчасы да булачак. Киләчәктә Каенсар авылында да күпфункцияле үзәк сафка басачак.

Хәер, программа нигезендә мәктәпләр генә төзелеп калмый. Шушы еллар эчендә 1,2 мең гаилә өчен 70 мең квадрат метр торак тапшырылган, шул исәптән 57 чакрым автомобиль юлы салынган. Моннан тыш, өч авыл клубы һәм ике мәктәп ремонтланган, физкультура-савыктыру комплексы, ике күпфункцияле үзәк, ике фельдшер-акушерлык пункты, биш спорт объекты төзелгән, шулай ук 50 километр озынлыкта су белән тәэмин итү һәм 10 километр озынлыкта су бирү челтәрләре сузылган.

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, республикада 3,9 млн кеше яши, шуларның 23 проценты, ягъни 900 меңгә якыны авыл территорияләрендә гомер итә.

– Программаның максаты – социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү нигезендә авыл халкының тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү, демографик вазгыятьне яхшырту өчен шартлар тудыру, авылларда хезмәт базарын киңәйтү, – ди Марсель Мәхмүтов.

Россия авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев әйтүенчә, авыл территорияләрендә якынча 37 млн кеше яши, бу Россия халкының дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

– Шуңа бәйле рәвештә, авылда заманча уңайлы яшәү шартларын булдыру дәүләтнең иң мөһим бурычларының берсе булып тора, аның актуальлеге хәзер арта гына бара, – ди ул. – Аны хәл итү өчен 15 дәүләт программасына нигезләнгән ярдәм чаралары гамәлгә ашырыла. Алар социаль объектлар һәм инфраструктура объектларын төзү, ремонтлау, реконструкцияләү темпларын һәм масштабларын арттырырга ярдәм итте. Белем алу, торак, медицина ярдәме күрсәтү, авылны квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү проблемалары хәл ителә. Социаль-икътисади үзгәрешләрне анализлау кулланылучы чараларның нәтиҗәле булуын күрсәтә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

COVID-19

Тынгысыз көз

Соңгы арада коронавирус инфекциясе турында сирәк ишетсәк тә, әле ул юкка чыкмады. Вирус әле дә бөтен дөнья буенча меңләгән кешенең гомерен өзә, организмны зарарлый. Шунысы да бар: Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы белгечләре сентябрь аенда коронавирус инфекциясеннән үлүчеләр санының пандемия тарихында иң түбән күрсәткечне тәшкил иткәнне белдерә.

Россиянең коронавируска каршы көрәш буенча оператив штабы мәгълүматларына караганда, соңгы айларда ил күләмендә көн саен 30–40 меңләп кеше әлеге инфекцияне йоктыра. Узган тәүлек нәтиҗәләре исә мондыйрак: 21094 яңа очрак, 3038 кеше хастаханәгә озатылган, 107 кеше үлгән, 45437 кеше сәламәтләнгән.

Чирләүчеләр санының азмы-күпме кимүен күрми калу мөмкин түгел. Бу хакта Роспотребнадзор идарәсе дә әйтә. Идарә башлыгы Анна Попова сүзләренчә, быел коронавирус үзен сезонлы вируслар кебек үк тота.

– Ел саен 1 сентябрьдә мәктәпкә, уку йортларына, оешмаларга кешеләр җыела. Ел саен бу кискен респиратор инфекцияләр дулкынының күтәрелешенә китерә. Быел коронавирус шушы дулкын белән туры килде дә. Без менә инде икенче атна әлеге инфекция белән чирләүчеләр санының кимүен күзәтәбез, – диде Анна Попова.

Татарстандагы саннарга килгәндә, республикада соңгы тәүлектә чир йоктыруның 350 очрагы теркәлгән. 65 кешене хастаханәгә салганнар. Узган тәүлектә 676 кеше сәламәтләнгән. Үлүчеләр юк.

Алга таба ни булыр соң? Табиб-инфекционист Николай Малышев әйтүенчә, кышка коронавирусның яңа дулкынын көтәсе. «Пандемия тулысынча бетмәде, ул күзәтеләчәк, кыш башында исә, гадәттәгечә, барлык респиратор инфекцияләрнең үсеше көтелә. Коронавирус та – респиратор инфекция, шуңа күрә, минемчә, киләсе дулкын көз азагы – кыш башына туры киләчәк», – дигән ул.

Тынычланырга сәбәп булмавын башка белгечләр дә әйтә. «COVID-19 кешенең тотрыклы патогенына әверелде инде. Мөгаен, ул кешелектән беркая да китмәс. Сезонлылыгы да юк аның. Кайчан да булса, бәлки, даимилеге булыр, әмма әлегә бу хакта әйтү мөмкин түгел. Иммунитет дәрәҗәсе 100 процентка якынайганда, вируска үсеш алырга һәм пандемиянең башындагы кебек үк интенсивлык күрсәтергә авыррак булачак», – ди Гамалея үзәге директоры урынбасары Денис Логунов.

САН

Хопкинс исемендәге университет мәгълүматларына караганда, дөньяда коронавирус белән чирләүчеләр саны 618562596 кешегә җиткән. Барлыгы 6548615 кеше үлгән. Чирләүчеләр саны буенча алдынгылыкта АКШ (96438726), Һиндстан (44599466), Франция (35701024), Бразилия (34684529), Германия (33386229) илләре тора.

Киләчәк нигезе

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Яшь укытучыларны 1970–1980 нче елларда белем биргән мөгаллимнәр белән чагыштырып: «Без укытканда, алай түгел иде, хәзер бөтенләй үзгәрде, укытучының абруе төште», – диючеләр белән килешмим. Укытучының гына түгел, безнең илдә шәхеснең абруе төшү күзәтелә. Бар нәрсә үзгәргәндә, укытучы гына үзгәрми кала алмый. Шуңа карамастан, без укытучыларны хөрмәт итәбез, – диде Илсур Һадиуллин. – Бүген дәүләт бүләкләренә лаек булган мөгаллимнәрне Кремльдә Президентыбыз үзе кабул итеп, бүләк тапшырды. Аларга бәя биреп, рәхмәт әйтү ул бөтен педагогик хезмәткәрләргә рәхмәт әйтү белән бер. Безнең республикада 76 меңнән артык мәгариф хезмәткәре эшли. Системада исә 150 меңнән артык хезмәткәр дигән сүз. Пешекчеләр, идән юучылар – барысы бала тәрбияләү эшендә катнаша, шуңа күрә без барысын да котлыйбыз.

Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур ҺАДИУЛЛИН мөгаллимнәрне Халыкара укытучылар көне уңаеннан котлады.

«Кадерле укытучылар, хөрмәтле мәгариф өлкәсе хезмәткәрләре, педагогик хезмәт ветераннары! Сезне ихлас күңелдән һөнәри бәйрәмебез белән тәбрик итәм. Укучыларыгызның уңышлары, әти-әниләрнең хөрмәте сезне яңа җиңүләргә рухландырсын, бетмәс яшәү көче бирсен. Һәрчак гаиләләрегездә иминлек, күңелләрегездә тынычлык, йөзләрегездә бәхет чаткылары булсын, – диелгән котлауда. – Үз гомерен иң изге эшкә – мөгаллимлек хезмәтенә багышлаган шәхесләргә карата ихтирамның тирәнлеген ачып бирә алырдай сүзләр табу җиңел түгел. Тормышта үз юлыбызны табарга, сәләтебезне ачарга ярдәм иткән мөхтәрәм остазларыбызны без гомер буе олы хөрмәт хисләре белән искә алабыз.
Яхшы укытучы – энҗе бөртеге кебек, кайда гына булса да, үз сыйфатларын югалтмый. Кояш юмартлыгы белән күңел җылысы өләшә, пәйгамбәрләр ихласлыгы белән белем тарата, аналар сабырлыгы белән шәхес тәрбияли. Милләт язмышы, илебезнең киләчәге – һәрвакыт мөгаллимнәр кулында. 2023 ел илебез күләмендә Укытучылар һәм остазлар елы дип игълан ителде. Бу – һөнәребезнең мөһимлеген, киләчәкне төзүдәге әһәмиятен тану һәм хезмәтебезнең җаваплылыгына тагын бер кат игътибар юнәлтү».

ЯШӘП ТУЮ

ТАТАРСТАНДА ҮЗ-ҮЗЕНӘ КУЛ САЛУЧЫЛАР САНЫ АРТА

Рухыбыз саумы? Белгечләр республикада үз-үзенә кул салучыларның саны артуга борчыла. Араларында яшьли яшәп туючылар – балигъ булмаган балалар да шактый. Моның сәбәбе нидә? Якыннарыбызны, балаларыбызны мондый адымнан саклап калу өчен без нәрсә эшли алабыз?



vk.com

САН

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы (ВОЗ) мәгълүматларына караганда, ел саен дөньяда **700** меңнән артык кеше үз-үзенә кул сала. Ягъни һәр **100** үлемнең берсе үз-үзеңә кул салуга туры килә. Белгечләр ачыклаганча, яшәп туючыларның күпчелеге – ир-атлар. Дөньяда суицидлар саны буенча Россия беренче унлыкка керә.

Бу һәм башка сорауларга 10 октябрь – Бөтендөнья психик сәламәтлек көне алдыннан оештырылган матбугат очрашуында җавап бирергә тырыштылар.

Нигә арта?

Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсенең табиб-психиатры Раил Гарипов сүзләренә караганда, Татарстанда соңгы өч елда үз-үзенә кул салучыларның артуы күзәтелә. Узган ел мондый очракларның саны 935 булган. Ә бу елның башыннан, ягъни тугыз ай эчендә инде 921 очракны теркәгәннәр.

– Шуларның 72се – балигъ булмаган балалар. Чагыштыру өчен: 2021 елда балалар арасында суицид очракларының саны 78 иде, – дип аңлатты ул.

Суицид яки үз-үзеңә кул салу – аутоагрессиянең, ягъни үз-үзеңә зыян салу, үз-үзеңне ничек тә булса рәнҗетергә тырышу, гаепләүнең соңгы чиге. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе табиб-психотерапевты Юрий Калмыков сүзләренә караганда, аутоагрессия билгеләре психик яктан сәламәт кешеләрдә дә булырга мөмкин.

Үзегезнең яки балаларыгызның борчулары булганда, психологик яктан белгеч ярдәме кирәк чакта, «Сердәш – 129» ашыгыч психологик ярдәм хезмәтенең **8 (843) 279-55-80** номеры буенча «кайнар линиясе»нә шалтырата аласыз.

Яшәүдән тую, үз-үзеңә зыян китерергә теләүнең һәм, гомумән, җәмгыятьнең рухи яктан көчсезләнүенең сәбәбе нидә соң? Белгечләр фикеренчә, психик сәламәтлеккә йогынты ясаучы факторларның исемлеге соңгы арадагы вазгыятькә бәйле рәвештә тагын да арткан. Тормыш артык тиз үзгәрә, бар кеше дә бу үзгәрешләргә яраклашырга өлгерми. Шуңа бәйле рәвештә, стресс, борчулар арта.

– Мәгълүмат артык күп. Кызганыч, адәм баласы барлык хәбәрләр арасыннан начарларын эзләп табып, игътибарын күбрәк шуңа юнәлтә. Бу – безнең төп проблемаларыбызның берсе. Безгә мөрәҗәгать иткән 20–35 яшьтәге кешеләрне алсак, алар күбесенчә эштәге уңышсызлыклардан, гаиләдәге мөнәсәбәтләрдән, матди тотрыксызлыктан зарлана. Якыннарының аңламавы һәм хәтта аңларга тырышмавы – шулай ук киң таралган проблема, – дип сөйләде Рамил Гарипов.

Ишетмибез

Иң аянычы – балаларның да тормыштан туюы, чәчәк кебек гомерләре белән хушлашырга ашыгуы.

– Төп сәбәпләрнең берсе – мәктәптәге проблемалар. Классташлары белән начар мөнәсәбәттә булу, буллинг, начар уку – барысы да балага тискәре йогынты ясый, рухи сәламәтлеген какшата. Тагын бер сәбәп – өйдәге мохит, гаиләдәге мөнәсәбәтләр, тәрбия. Кызганыч, әти-әниләр баланың рухи халәте белән кызыксынмый. Һич югы, көненә бер мәртәбә булса да: «Көнең ничек узды?» – дип сорарга кирәк, – ди Рамил Гарипов.

Юрий Калмыков фикеренчә, әти-әниләргә балаларын ишетергә өйрәнергә кирәк.

– Баланың үз-үзен тотышындагы үзгәрешләренә игътибар итәргә кирәк. Балагыз начар укый башласа, үз эченә бикләнсә, аны гаепләргә ашыкмагыз. Күп кенә әти-әниләр «Тагын нәрсә җитми инде сиңа?», «Бөтен нәрсәң бар бит, нигә кәефсезләнеп йөрисең?» кебек сораулар бирә. Балаларына психологик ярдәм кирәк икәнен аңламый. Аңласа да, белгечләргә мөрәҗәгать итми. Бу – бик зур проблема. Балага вакытында ярдәм күрсәтеп өлгерергә телисез икән, мондый нәрсәләргә күз йоммагыз. Соңгы арада безгә мөрәҗәгать итүче үсмерләр саны артты. Һәм, беләсезме, аларның кайберләре әти-әнисеннән качып мөрәҗәгать итә. Бала аңлый, ә әти-әни аңламый!

Рамил Гарипов бүгенге үсмерләрнең күп нәрсәне анализларга сәләтле булуын, җәмгыятьтәге сәяси вакыйгаларга битараф кала алмавын да искәртте.

– Алар да нәкъ өлкәннәр кебек борчыла. Киләчәкләре турында уйлый. Бу шулай ук начар уйларга китерергә мөмкин. Моннан тыш, без баланың рухи халәтенә интернет, компьютер уеннары да начар йогынты ясый, агрессия дәрәҗәсен күтәрә, дигән фикерне еш ишетәбез. Ләкин бу һәрвакыт алай түгел. Янә гаиләдәге мохиткә әйләнеп кайтыйк. Виртуаль чынбарлыкны кабул итүдә әти-әни тарафыннан бирелгән яки бирелми калган тәрбия дә зур роль уйный.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

УКУЧЫ СҮЗЕ



Илдар Мөхәммәтҗанов

ҺӘР ФАСЫЛНЫҢ ҮЗ МАТУРЛЫГЫ...

Бу дөньяның көзләре дә матур...
Киткән кошлар, әйдә, китсеннәр,
Үткән гомерең кире кайтмас диеп,
Баш очымнан, әйдә, үтсеннәр.
Кошлар, әйдә, ташлап китсеннәр!

Көзләрнең бит язлары да була,
Китүләрнең була кайтыры.
Яннарымда син каласың әле,
Синең белән дөнья матур ул!

Синең белән без йөрегән юлга
Киткән кошлар юлы тиңмени?
Синнән башка гомерем ямьсез минем,
Синнән башка мин ул минмени?

Үткән гомер кире кайтмаса да,
Киткән кошлар кире кайтыр ул;
Бу дөньяның көзләре дә матур,
Син булганга шулай матур ул.
Киткән кошлар кайтыр,
кайтыр ул!

Әнгам АТНАБАЕВ

Сезне сайлар идем

Кечкенәдән укытучы булырга хыяллана ул. 1994 елда Башкортстандагы Имәнлекул урта мәктәбен тәмамлап, хыялын тормышка ашырырга Бөре педагогия институтына укырга юнәлә. Шуннан туган мәктәбенә кайта. Аның хезмәт кенәгәсендә бер генә язу – Имәнлекул урта мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы.

Яшь кенә булса да, тәҗрибәле, эшен яратып-сөеп, бар күңелен биреп башкаручы олы хөрмәткә лаеклы беренче укытучым Гөлнара Мәдих кызы Галимуллина турында бүгенге язмам.

2011 ел минем күңелемә шул чаклы уелып калды: без бу елны «Кояшкай» балалар бакчасыннан беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап кердек. Август аендагы күңелле мәшәкатьләр бик кызыклы, мавыктыргыч булып исемдә калган. Миңа иң кызыгы, ә әти белән әнигә, бәлки, иң авырыдыр, мәктәп күлмәге эзләү булды. Буем бик кечкенә булу сәбәпле, ярашлысын эзләп, якын-тирә Чакмагыш, Дүртөйле, Яркәй базарларын урап та тапмагач, Уфага юл тоттык. Әти белән әни иң бәләкәй үлчәмле мәктәп күлмәге табуга сөенсә, мин, шуны эзләп, ике көн сәяхәттә йөрүемә шатландым.

Беренче сентябрьнең кояшлы, салкынча иртәсендә, аллы-гөлле гөлләмәләр тотып, 11 нче сыйныфта укучы апам Эльвирадан калышмаска тырышып, йөгерә-атлый мәктәпкә юл тоттым. Бер ягымнан әнием сумкамны күтәреп атлады. Шау-гөр килеп торган мәктәпкә барып кергәч, югалып калдым. Әнием, мине җитәкләп, класс бүлмәсенә озатты, ә анда, елмаеп, беренче укытучым Гөлнара Мәдих кызы каршы алды. Беренче күрүдә үк күңелемә үтеп керде ул.

Унөч укучы, укытучыбыз белән җитәкләшеп, мавыктыргыч белем дөньясына юл тоттык. Аның кул астында укырга, язарга өйрәнүләребез, бергәләп походларга чыгуларыбыз, класс белән бәйрәм саен концертларда укытучыбыз өйрәткән биюләр, җырларны башкаруыбыз балачактагы матур хатирә булып калдылар.

Гөлнара Мәдих кызы укыткан барлык сыйныфлар балаларның да, ата-аналарның да дустанә мөнәсәбәте белән аерылып тора. Ул укучыларын төрле яклап камилләштерергә омтыла, җылы сүзен, ягымлы карашын җәлләми. Аның укучылары олимпиадаларда, конкурсларда, төрле иҗади чараларда катнашып, призлы урыннар яулый. Башлангыч сыйныфларда ук калын папкадагы грамоталар – һичшиксез, Гөлнара Мәдих кызының бәяләп бетергесез хезмәте. Укучылары белән беррәттән үзе дә актив җәмәгать эшчәнлеге алып бара, халык санын алуда, сайлауларда катнаша. Иң яхшы башлангыч сыйныф укытучысы конкурсында катнашып, җиңү яулый. «Ел укытучысы» бәйгесендә «Йөрәгемне балаларга бирәм» номинациясендә дә беренче урынны ала. Бик күп мактау грамоталары да бар аның.

Гөлнара Мәдих кызы, әйткәнемчә, бар булмышын мәктәпкә багышлый. Яратып кавышкан яры, Линар абый белән бик матур тормышта яшиләр. Ул күп итеп матур-матур чәчәкләр үстереп, авылда уздырылган «Иң матур йорт алды» бәйгесендә дә алдынгылыкны бирми. Яшелчә, җиләк-җимешнең дә күп төрләрен үстерә. Авылыбызның күркәм гаиләсе алар. Өлкән уллары Илназ – Уфа нефть университеты студенты, кечесе Риназ Имәнлекул урта мәктәбендә 8 нче сыйныфта белем ала. Үз вакытында Илназ мәктәпнең алдынгы укучысы булып, спорт ярышларында, район, республика, ил күләмендә олимпиадаларда катнашып, призлы урыннар алып йөрсә, хәзер инде ул эстафетаны энекәше Риназ дәвам иттерә. Бүләкләренә күз салсаң, хәтта абыйсын да узып киткән сыман тоела.

Барлык эшләре дә мактауга, хөрмәткә лаеклы укытучым белән чиксез горурланам, аның үзен дә, дәресләрен дә бик сагынам! Кешегә кабаттан яшәү, сайлау мөмкинлеге бирелсә, мин, һичшиксез, беренче укытучым итеп бары сезне сайлар идем, Гөлнара апа.

Суфия ШӘКҮРОВА.
КФУның I курс студенты

КҮҖӘКӘГӘ КИЛЕН ТӨШӘ

Әбиебез Нурфика Абдуллинаның ныклыгы, сабырлыгы, батырлыгы һәммәбезгә бик кирәк. Аңа быел 2 декабрьдә 96 яшь тула. Бөек Ватан сугышы ветераны. Азнакай районы Мәндәй авылы кызы.

Башлангыч белемне үз авылында ала, җиде сыйныфны Чубар Абдул мәктәбенә җәяү йөреп укый. «Иртәрәк килгән көннәрдә мәктәп ачылганын көтеп, туңып утыра идек. Оеклар бозланып ката, аякларны чуан баса иде», – дип искә ала ул.

1938 елда ул Минзәлә медицина училищесына укырга керә. Укыган өчен акча түләргә кирәк була ул вакытларда. «Көнбагыш сатып укыдым», – дип әйтә әбием. 1942 елның март аенда, белемлерәк укучыларны сайлап, районнарга эшкә җибәрәләр. Әбием, фельдшер таныклыгы алып, Калинин районы (хәзерге Актаныш районы) Пучы участок больницасына эшкә килә. Аны Күҗәкә җирлегенә фельдшер итеп билгелиләр. Бу авыл карамагына биш авыл: Буранчы, Үмәнәй, Адай, Түбән Урьяды, Югары Урьяды. Тирә-юньдә ачлык, ялангачлык, авырулар өчен кирәкле дарулар, материаллар җитешми, тиф башлана. Әбием үзе дә, авырып, больницада ята. Шундый авырлыклар алдында куркып, югалып калмый ул, булган белемен эшкә җигә. Зарланмый, ат табып, 15 чакрым ераклыкка авыруларны да илтә.

1943 елның сентябрь аенда аңа да повестка килә, 6 медик кыз Казанга юл тота. Казанда аларны төрле госпитальләргә урнаштыралар, шәфкать туташлары итеп билгелиләр. Ул эшләгән госпиталь 5868 нче номерлы була. Фронттан аяк-куллары яраланып кайткан солдатларны карый ул. Япь-яшь кызлар яралыларны носилкалар белән госпитальгә ташыйлар, җәрәхәтләрен бәйлиләр, тәүлек буе кизү торалар. Яралы солдатларны караудан тыш, хуҗалык эшләрендә дә актив катнашалар.

Госпитальне җылыту өчен баржадан утын да бушаталар. Шундый эш башкарганда, әбием әздән генә суга батмыйча кала, табельщиклар тотып өлгерәләр. Ул һушын югалта. «Аңыма килгәч, иптәш кызларым мине трамвай тукталышына кадәр сөйрәп алып кайттылар», – дип искә ала.

Бабам, Шәехов Әбүбәк белән 1942 елда Күҗәкә авылында эшләгәндә танышалар. Сугышка кадәр ул да Минзәләдә, педучилищеда укый. Укыган өчен акча түләтә башлагач, мөмкинлекләре булмау сәбәпле, ташларга туры килә. Пучыда хисапчылар курсын гел «5ле» билгеләренә генә тәмамлап, колхозда хисапчы булып эшли.

1943 елның гыйнвар аенда бабамны да сугышка алалар. 1949 елның март аена кадәр алар арасында хатлар гына йөри. Җиңү көнен Эстониянең Остров шәһәрендә каршылый.

Сугыштан соң ул озак еллар мәктәптә укытучы, мәктәп директоры булып эшли, авыл ветераннар советын җитәкли. Бабам 1994 елда вафат булды. Әбием белән алар 5 бала тәрбияләп үстергәннәр.

Бабай әбиемне Казаннан алып кайту вакыйгасын бик матур итеп сөйли иде. Әбине эшеннән җибәрергә теләмиләр. Бабам, сәламәтлек министры белән элемтәгә кереп, әбиемне авылга – Күҗәкәгә алып китә. Авыл инде аңа таныш, бу юлы ул килен сыйфатында кайта. 1977 елга хәтле авыл халкына хезмәт күрсәтә.

Гаиләдә бер-бер артлы 5 бала туа. Ярый каенанасы әйбәт була, балаларны тәрбияләргә булыша. «Кайбер вакытларда өйгә кайтып керергә өлгермим, артымнан килеп җитәләр иде», – дип сөйли ул. Килүчеләр күп була. Аллага шөкер, әбиебез – бүген дә безнең арада. Аның догалары кабул булып, барыбызга да тыныч илләрдә яшәргә язсын.

Ландыш СИРАҖЕТДИНОВА.
Актаныш

Уйлы күңел уйлана

Урта кул

Белүемчә, гел үзен генә кайгыртып яшәүче урта кул җитәкчелектә йөргән танышым белән гәпләшеп утырам. «Сине ничек гел дәрәҗәле урыннарда йөрттеләр?» – дип сорыйм.

– Соравың урынлы, – диде ул. – Дөрестән дә, мине совет чорында райком секретаре көчләп диярлек читтәге зур авылга колхоз председателе итеп куярга теләде, ә мин бармадым.

Аңа карап кына барыбер түбәнгә төшмәде бу урта кул белгеч-җитәкче дигәнебез, һичбер вакыт үзенә тел-теш тидерттермәде, гел ярап-яраклашып яшәде. Хәтта ки дәүләт бүләкләренә дә лаек булды. Пенсиясе дә өстен хәзер. Яше шактый югарыга үрмәләсә дә, ул аңа игътибар итми. Бабай булса да, көләч агай булып күренә. Кышын, җәен урман-болынлыкларда чын табигать баласы булып йөри, бик өлгер. Вакыт-вакыт, менә бу – чын гомер итү рәвеше инде, дип сокланып куясың. Сүз әйтә торган түгел бит.

Сарыкны кем ашаган?

Журналист халкын кайчак җиңеннән тартып куялар. Шулай бервакыт, бик күптән инде, район башлыгының «җитди киңәш»ләре колагымны ярып керде. «Нигә ул Вахитов совхозының «Руно» берләшмәсендә илгә танылган сарыкчылык комплексы бетүгә баруны «Социалистик Татарстан»ның беренче битендә «Сарыкны кем ашаган?» дип хур итәргә иде?!» – диде.

– Үзебездә үтмәгәч, республикабызның үзәк гәҗитенә җибәрергә мәҗбүр булдым, – дип җаваплыдым.

– Миңа әйтмичә, мондый эшләрне эшләмә, – диде ул. – Болай хурга калмыйк инде.

Шуннан соң ни гаҗәп: алга таба, шуның кебек язмалар район газетасында басыла да югары даирәләрдә яңгыраудан котылып кала торганга әйләнде. Уйлап карасаң, әйбәт бит: сарык та исән, бүре дә тук!

Үткән эшкә салават, бүгенгесе ничек, диярсез. Әллә чынлыкта бу алым билгеле түгел, әллә матбугатта тәнкыйтькә битарафлык хөкем сөрәме, андый язмалар урындагы газета битләрендә юк диярлек. Шул сәбәпле, проблема күтәргән язмалар үзеннән-үзе республикабызның төп басмасында урын ала.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай шәһәре

Тагын да якынайдык

Август башында без бик матур бәйрәмдә булдык. Нурлат районының Кәкре Атау авылында яшәүче дустыбыз Шәмсегаян Галәүетдинова шәҗәрә бәйрәме оештырды. Тумышы белән Салдакай авылыннан булган Шәмсегаян үз туган авылына әти-әнисе ягыннан алты буынга хәтле барлык туганнарын җыйды. Бу күркәм очрашуга йөздән артык кеше кайткан иде. Ерак шәһәрләрдән – Самара, Әлмәт, Чаллы, Казаннан кайткан кунаклар, бер-берсе белән кочаклашып, таныш булмаганнары танышып, туганлык җепләрен ныгытып таралыштылар.

Без бу чарага ахирәт дуслар буларак чакырылсак та, тормыш иптәшем Хәлилнең тамырлары алар нәселеннән булып чыкты. Бәйрәмнән соң без бер-беребезгә тагын да якынайдык. Әлеге бәйрәмне оештыруга Шәмсегаяннның бертуган энесе Хәсибулла Хәмидуллинның гаиләсе дә зур көч куйган. Шәмсегаян дустым 30 парә Коръән укыган. Аны Кәкре Атау авылы мулласы Мөнир хәзрәт бу нәселнең барлык мәрхүм туганнары рухына багышлады.

Күп еллар укытучы булып эшләгән Шәмсегаянның үз куллары белән чигеп ясалган зур шәҗәрә агачы бөтен кешене сокландырды. Бу очрашудан бик матур хисләр белән кайттык. Шәмсегаян кебек кешеләр булганда татар нәселе, гореф-гадәтләре, ислам дине югалмас. Әлеге чара барыбызга да үрнәк булсын иде.

Ләйсән һәм Хәлил ЗАҺИДУЛЛИННАР.
Нурлат

КҮЗЕ АЧЫЛМАГАН ПЕСИ ДӘ ЯРАТКАННЫ СИЗӘ

Рамил Туманов – ветеринар, терлекләрне дәвалаучы. Бу тынгысыз хезмәтне Ютазы районы авылларында инде уналты ел буена башкара ул. Кичме, төнме, таң аткан чакмы – сыеры бозаулый алмый, үгезнең мөгезе сынган, сарыкның авызыннан күбек килә, атның үзен тотышы ошамый, умарталарга нидер булган икән, һәрчак Туманов кирәк! Райондагы ун меңнән артык терлек, күпләгән каз-үрдәк, тавык, күркә – барысының да сәламәтлеге район ветеринарлары карамагында.

Урта мәктәпне тәмамлауга, бәхет эзләп, шәһәргә китмичә, тормышның нигезен тәшкил иткән терлекчелеккә юл тота ул. Алты яше тулар-тулмас әти-әнисе янына килеп, ферма маллары арасында буталып үскәндә үк, яңа сауган сөт тәме, яшел чирәм, басудан әле генә кайткан салам тузаны, сенаж-силосның хуш исенә иләнә сабый. Кечкенәдән мал табибы булырга хыяллана. Кайберәүләрнең күзенә дә чалынмый торган шушы хезмәттән, мал-туар арасында йөрүдән тәм табып яши. Авыру хайванны күзләреннән аңлый ул. Яңа туган бозау, ярсыган үгез, күзе ачылмаган песи баласының да хәленә керә белә.

Гадәттә ветеринарлар турында күп язарга, мактап искә алырга яратмыйлар. Югыйсә зур уңышка ирешкән, орден-медальләр таккан савымчыларның эше аларның хезмәтенә турыдан-туры бәйле бит.

– Терлекчелектә сыйфатлы, мул азык җитештерүне беренче чиратта кадрлар хәл итә. Бу хезмәткә төшенү генә, хәтта дипломлы белгеч булу гына да аз. Теләк, белем, тәҗрибә, тиешле шартлар, санитария таләпләрен тайпылышсыз үтәү – боларның барысы да зур җаваплылык белән башкарылса гына яхшы нәтиҗәгә ирешеп була, – ди тәҗрибәле белгеч. – Һәм тагын бер мөһим шарт: читтән мал сатып алу һәм үз районыңа кертү эше дәүләт карамагында булырга тиеш. Бу – авыруны булдырмау, таратмау өчен бик кирәкле чара.

Рамил Рәшитович турында иптәшләре дә яхшы фикердә.

– Туманов – районда белемле, тәҗрибәле, көчле белгеч. Аның белән аралашу, киңәшләшү ышанычны арттыра, үз хезмәтебезгә, ветеринарларга хөрмәт уята. Яхшы белгеч кенә түгел, көчле ихтыярлы шәхес тә ул, – ди райондагы абруйлы хуҗалык җитәкчесе Ансель Вафауллин.

Нурия ХӘКИМОВА

АВЫЛ ХӘБӘРЧЕСЕ

Тәкыя апа Шәрипованың актив иҗат иткән еллары минем күз алдында үтте. Урсай сигезьеллык мәктәбендә ул минем сыйныф җитәкчем иде. Соңрак бергә эшләргә дә, иҗат итәргә дә насыйп булды. Күп нәрсәләргә аннан өйрәндем, өлкән остазым да, киңәшчем дә иде ул. Тәкыя апа бик күп күренекле шәхесләр белән аралашып яшәде. «Ватаным Татарстан» (элекке «Социалистик Татарстан») газетасының күренекле журналисты Габделбәр Ризванов студент чагында, авыл хәбәрчесенең тәҗрибәсен өйрәнергә дип, аны эзләп, өенә килде. Күренекле язучы һәм радиожурналист, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Мидхәт Миншин, авылыбызга килеп, 1970 нче еллар ахырында Тәкыя апага багышлап «Йөрәк картая белми» дигән радиоочерк эшләде һәм аны эфир дулкыннары аша илгә яңгыратты. Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, язучы Мәхмүт Хәсәнов Азнакайда яшәгән елларында җәмәгате Мәрьям ханым белән җәй айларында һәр атнада диярлек Тәкыя апа һәм аның ире – педагог һәм сугыш ветераны Миргасим абый Шәриповларда кадерле кунак иде. Авылыбызга терәлеп агучы Ык елгасы балыкка йөрергә яраткан Мәхмүт аганың төп ял урыны булды. Без бала чакта авыл клубында күргән беренче тере язучы да ул иде. Аның укучы балалар алдында артистларча осталык белән үзе укыган «Ярты алма» хикәясе бүген дә колакта яңгырап тора. Тәкыя Шәрипова 1922 елда Татарстанның Ютазы районы Кара Зирек авылында туа. 1940 елда Бөгелмә шәһәрендә педучилище тәмамлап,

Рәсемдә (уңнан сулга): язучы Мәхмүт Хәсәнов, аның җәмәгате Мәрьям ханым, Тәкыя Шәрипова һәм ире Миргасим ага (1970 еллар уртасы)

Баулы районы Хансөяр мәктәбендә татар һәм рус телләре укытучысы, завуч булып эшли. Өч елдан соң элеккеге Тымытык, хәзерге Азнакай районы Урсай авылына күчеп, лаеклы ялга чыкканчы балалар укыта, «халык мәгарифе отличнигы» исемен ала. 1950 елда Казан педагогия институтын тәмамлый. Татарстан хөкүмәтенең Мактау грамотасы белән бүләкләнә. 1974 елда эшче һәм авыл хәбәрчеләренең V республика съезды делегаты була. Ул – Азнакай хакимиятенең Мәхмүт Хәсәнов исемендәге премиясе лауреаты. 1998 елда «Сөембикә» журналы үткәргән «Гасыр чаңы ни хакында?» дип аталган бәйгедә Тәкыя Шәрипова беренче урынны яулый.

Танылган шагыйрь, СССР Министрлар Советы премиясе лауреаты Илдус Гыйләҗев укытучысы турында болай дип язган иде:

«Алдымда Тәкыя Шәрипованың 2001–2002 елларда Чаллы һәм Казан шәһәрләрендә нәшер ителгән «Күңелем җәүһәрләре» һәм «Ык буйлары – гомер бишегем» китаплары. Минем укытучым шигырьләре... Укыйм да моннан 45 ел элек хәерле тормыш юлы теләп озатып калган Укытучымны күз алдына китереп утырам. «Дилбегә тотар өчен белем кирәкми», – дип ышанып йөргән без, авыл мокытларын, Пушкин, Лермонтов, Тукай, Җәлил иҗаты белән таныштырды, җөмлә төзергә өйрәтте...

Аның шигырьләре кемнәрнедер шаккатырыр өчен язылмаган. Шигырьләрдә – Тәкыя апаның дөньяга карашы, уй-кичерешләре, җирдә яшәүнең, Ык буйларының матурлыгы, җәмгыятьтәге бүгенге үзгәрешләрне кабул итеп бетермәү, балаларына әйтәсе килгән сүзләре, шәкертләренә мөнәсәбәте, кимчелекләрне күргәч ачынулары һәм башкалар.

Кешеләрне, илне яраткан шәхес кенә шулай яши».

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә Фәйрүзә Исмәгыйлова Тәкыя апаның «Ык буйлары – гомер бишегем» шигырьләр җыентыгына кереш сүздә болай дип язды:

«Бигрәк пөхтә, матур инде безнең татар ханымнары, дип уйлап куйдым мин, аның белән танышып күрешкәннән соң. Башына укалы ап-ак яулык бөркәнгән, зәңгәр күлмәгендә – эреле-ваклы мәрҗәннәрдән торган төймә. Салават күпере төсләрен чагылдырып, кояш нурында коена алар. Юк, төймә түгел, бер гасырга якын гомер тәҗрибәсе булган күңеле чагылдырадыр ул төсләрне. Һәм ул төсләр, хисләр рәвешен ала да, шигырь булып дөньяга туадыр».

Исән булса, бу җәйдә авыл хәбәрчесе Тәкыя Шәриповага 100 яшь тулган булыр иде. Шул уңайдан Урсай авылы мәдәният йортында китапханәче Флүзә Мөнихова искә алу кичәсе үткәрде. Авылдашлары Тәкыя апаны яхшы хәтерли, әле аның вафатына да күп вакыт үтмәде – ул 2013 елның декабрендә дөнья куйды. Портреты авыл клубы диварын бизәп тора.

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ.
Азнакай

Язучы фикере

Балалары җавапсыз кала

Бишектә яткан баланы кулыңа аласың, күтәреп йөртәсең, коляскага саласың, киендерәсең, чишендерәсең… Ул сиңа карышмый. Еламый да, тыпырчынмый да. Кайчагында елмаеп тик ята. Ул сиңа ышана. Тәпи басып, теле ачылса да, ул синең ихтыярга буйсына. Җитәкләп, каядыр алып барасың. Ашыктырасың. Ул каршы килми. Ышана. Сиңа.

Сабый бала әти-әнисенә ышанган шикелле үк ата-анасы да, олыгая башлагач: «Картайган көнемдә балаларым таяныч булыр», – дип уйлый. Шуңа өметләнә. Ышана. Сабый бала кебек ышана. Тик кайвакыт өметләре өзелә, ышанычлары салкынлыкка бәрелеп чәлпәрәмә килә…

Ходайның бер хикмәте микән инде ул, бүтән сәбәбе бар микән, миңа бай язмышлы кешеләр еш очрый. Ачылып китеп, эч серләрен сөйләп ташлыйлар. Киңәш сораган чаклары да була. Мин тыңлыйм. Юатырга тырышам. Һәм бу сөйләшүләрне куен дәфтәренә теркәп куям. Монысы инде – язучының бер кимчелеге: онытылмасын, бәлки, берәр әсәрдә кулланырга туры килер, дигән исәп. Менә шундый язмалар күп җыелып киткән. Бүген берсен сезгә дә тәкъдим итәсем килә.

– Олыгайгач, балалар безнең дөньяда барлыкны да онытты, – ди ул, авыр көрсенеп. – Кешегә әйтергә дә оят инде, бер карасаң. «Дөрес тәрбия бирмәгәнсез, үзегез гаепле», – диячәкләр. Бәлки, чынлап та шулайрак булгандыр инде ул, тәрбиягә вакыт та җитеп бетмәгәндер…

Унсигез яшендә үк институттагы төркемдәш егетенә кияүгә чыга ул. Яратышып йөриләр. Мәхәббәт хисе бер котырса, дөньяңны оныттыра бит инде. Ул да авырга уза. Уку дип аборт ясатып булмый бит инде. Өйләнешәләр, кызлары туа. Сокланып туймаслык бала инде шундый, кара чәчләр, чем кара күзләр. Ходайның бүләге шикелле тоела. Ире, укуын калдырып торып, эшкә урнаша. Хатын академик ял ала, шуннан укуын дәвам иттерә.

Тормышлары беркадәр көйләнә башлый. Ә ул арада хатын тагын авырга уза. Ике бала үстерү һәм укуыңны дәвам иттерү уен түгел. Тырышырга туры килә инде. Ире берничә урында эшли, гаиләне тәэмин итәргә тырыша. Акча барыбер җитми. Шулай да иренә эшеннән фатир бирәләр. Үз куышың булгач, барысы да җайланган кебек тоела. Хатын читтән торып укуга күчә. Көч-хәл белән укуын тәмамлый. Эшкә урнаша. Тырышулары юкка чыкмый инде, әкренләп кенә барысы да әйбәтләнә төшә. Балаларының өс-башы караулы, тамаклары тук. Хәтта ике елга бер булса да бөтен гаиләләре белән диңгез буенда ял итеп кайтырлык та рәтләре табыла.

Бераздан хатын тагын кыз бала алып кайта…

– Ничек көч-куәт тапканбыздыр, хәзер үзем дә аптырап куям, – дип, моңсу елмая ханым. – Ирем уңган кеше булды инде, тырышты. Көненә биш-алты сәгатьтән артык йокы күрмәгән чаклары да еш була торган иде. Әллә ничә төрле эштә эшләде. Дөньяны бөтәйтергә, балаларны ким-хур итмәскә тырышты. Хәзер бит аның заманча телефоны да, компьютеры да, башкасы да кирәк. Акча җиткерә алмаганда, кредитка да баткаладык. Аны тагын ерып чыктык.

Олы кызлары, мәктәпне тәмамлап, институтка керә. Түләүле бүлеккә. Билбауларны ныграк кысып, бераз тын алган кебек булсалар, ул кияүгә чыгарга җыенуын әйтә. Егет әйбәт гаиләдән булгач, каршы килеп тора алмыйлар инде. Хәер карышып та булмыйдыр, яшьләр арасына кереп, кем бәхеткә тиенгән? Туйны зурдан кубып уздыралар. Гомергә бер генә килә торган вакыйга бит инде, истә калырлык дәрәҗәдә булырга тиеш. Аннан соң өлкән кызларына фатир сатып алып бирәләр. Нык кына казганып, тырышып-тырмашып, әлбәттә. Ләкин үз балаң өчен бернәрсә дә жәл түгел. Үз фатиры булмаган килеш, яшь гаилә бәхетле яши аламыни?!

Бурычларын түләп бетерүгә, малайлары үсеп җитә. Апасына ничек ярдәм итүләрен күреп торгач, аны да үгисетеп булмый бит инде. Аңа да бер бүлмәле фатир алып бирәләр. Кредитны алу гына рәхәт, түләү кыен. Әмма үз балаң өчен бит, үз улыңа берни кызганып булмый.

Кече кызлары фатир сорамый. Ул чит илдә укырга теләвен генә әйтә. Тик монысы да – күп акча таләп итә торган нәрсә. Автомобильләрен сатып, тегеннән-моннан бурычка батып, аны да түләргә туры килә.

Боларның тормышында әллә ни яңалык юк бугай инде. Хәзерге көн өчен гади һәм бик гадәти күренеш. Бала-чаганың күбесе үз-үзен тәэмин итә алмый хәзер. Әйбәт эшкә урнашу да бик җиңел түгел бугай, хезмәт хакын күп җирдә кредит түләрлек һәм ачтан үлмәслек кенә итеп бирергә тырышалар бит. Заман үзенчәлекләре дә, объектив һәм субъектив сәбәпләре дә бардыр. Ләкин чынбарлык шундый.

Тик бу ханымның бер генә үзенчәлеге бар. Олыгая төшкәч, әтиләре чиргә урала. Гомер буена бер эштән икенчесенә чабып йөрү эзсез генә узмый торгандыр, адәм мөмкинлекләре дә чиксез түгел бит. Паралич сугып, түшәктән тора алмас хастага әверелә. Хатын, аны карар өчен, эшеннән китәргә мәҗбүр була.

Һәм иң гаҗәбе… Балаларының берсе дә, килеп, әтисенең хәлен белми. Өлкән кызлары бер-ике тапкыр телефоннан шалтыратып зарланып ала: «Вакыт юк, бернигә дә өлгерә алмыйм. Йорт, эш, гаилә…» Хәтта әтисенең хәлен дә сорашмый. Малайлары телефонын да алмый. Үзе дә шалтыратмый. Килеп, хәл белешеп китү турында әйтәсе дә түгел. Кече кызлары чит илдә булгач, кайтып урап китә алмый. Ярый, анысын, бәлки, гафу итәргә дә мөмкиндер, әти-әнисе шулкадәр акча түгеп кергән укуыннан аерылырга теләмидер.

Мондый хәлләр элек тә булгалаган инде, минем «Бердәнбер һәм кабатланмас» романы да шундыйрак күренешкә корылган иде. Ләкин соңгы арада ешая төшкән кебек тоела. Хәтта андый ук чиккә барып җитмәсә дә, ата-анага булган мөнәсәбәт беркадәр үзгәрде, аларның бәясе тәгәри башлады. Әти-әниләре: «Балаларым ким-хур булмасын, без күргән михнәтләрне күрмәсеннәр», – дип, бөтен гомерен, бөтен сәламәтлеген аларга багышлый, ә балалары җавапсыз кала. Гаиләдәге тәрбия белән генә аңлатып була микән моны? Илгә килгән авыру түгелме икән?

Бер сүз әйтеп булмый бугай инде. Ни дисәң дә, хата булыр сыман.

Марат КӘБИРОВ

«КҮҢЕЛ» ЕЛДАН-ЕЛ ЯШӘРӘ

Чаллының «Күңел» радиосы инде чирек гасыр дәвамында 92,6 ешлыгы аша көн саен Кама аръягы төбәгендә яшәүчеләрне сәламли. Аларны радиоалгыч аша гына түгел, концертлары аша да яхшы беләләр. Тиздән «Күңел» Казан тамашачысы белән дә очрашачак.

Радионың киләчәккә уй-ниятләре, рекордлары һәм яшь алып баручылары турында «Күңел»нең җитәкчесе Лилия МӘХМҮТОВА белән сөйләштек.

vk.com/kunelradio

:: Лилия ханым, тиздән «Күңел» радиосы Казан тамашачысына үзенчәлекле концерт тәкъдим итәчәк. Шул концерт турында сөйләгез әле.

– Быел радио үзенең 25 еллык юбилеен уздыра. Шул уңайдан республиканың төрле районнарына барып, концертлар куярга карар кылдык. Үзебезнең тирәдәге генә түгел, әлегә безнең ешлык тотмаган районнарга да барасыбыз килде. Бу ниятебезне беренче булып Арчада тормышка ашырдык – җәйге кичтә урам концерты оештырдык. Аннан, уйлаштык-уйлаштык та, Казанга да барып кайтырга кирәк дигән фикергә килдек. Казан тамашачысының зәвыклы икәнен бик яхшы беләбез, шуңа да гади концерт түгел, үзенчәлекле тамаша әзерләдек. Шулай итеп, 26 октябрьдә «Уникс» концертлар залында шәһәр халкын һәм кунакларны яшьлек елларына алып кайтачакбыз. Концертта һәркемгә якын һәм таныш булган җырлар яңгыраячак. Әти-әни канаты астында узган гамьсез чакларны искә төшерү, шушы вакытларга берничә сәгатькә булса да кайтып килү ниятеннән уздырабыз без ул концертны.

> «Безнең яшьлек җырлары» концертында халкыбызның яраткан артистлары Зәйнәб Фәрхетдинова, Зөфәр Билалов, Эльвира Хәйруллина, Рөстәм Закиров, Гөлдания Хәйруллина, Сәгыйть Гыйбашев, Асаф Вәлиев, Асыльяр, Рәсим Низамов, Зөһрә Шәрифуллина, Айрат Гомәров, Илназ Минвәлиев, Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар, Рамил Миндияр, Зөфәр Хәйретдинов, «Айфара» төркеме, «Мунча ташы» эстрада театры, Руслан Кираметдинов, Әлфинә Әзһәмова һәм Казан тамашачысы өчен иң зур бүләк – Дәниф Шәрәфетдинов катнашачак.

Катнашучыларны кемнең нинди артист булуына түгел, нинди җыр башкарачагына карап сайладык. Чыгыш ясаучылар арасында яшьләр дә бар. Алар 80–90 нчы елларда популяр булган җырларны башкарачак.

:: Юбилей, димәктән, «Күңел» 25 еллыгын нинди нәтиҗәләр, уй-ниятләр белән каршылый?

– Нәтиҗәләрне без һәр сезон саен ясыйбыз. Барын да уртага салып сөйләшәбез. Булган проектларга бәя бирәбез, яңалары турында уйлыйбыз. Шушы еллар дәвамында шуны аңладык: тыңлаучылар үзгәрә, шуңа күрә без дә үзгәрергә тиеш. Уй-ниятләргә килгәндә, моннан биш ел элек безнең радио Кама аръягы төбәге өчен генә эшләсә, хәзер безне Мамадыш, Арча, Буа һәм Биектау районнарында да тыңлыйлар. Киләчәктә исә, моның белән генә чикләнмичә, үз ешлыгыбызны республиканың башка районнарында да булдырырга, тыңлаучыларыбызны арттырырга телибез. Безгә бу турыда язучылар да, онлайн тыңлаучыларыбыз да шактый. Шуларны бер йодрыкка туплыйсы иде.

:: Сез бит әле юбилей уңаеннан радиомарафон уздырып, Гиннесс рекордлар китабына да керергә җыенган идегез.

– Әйе, җәй көне без 30 сәгатьлек радиомарафон уздырдык. Башта гел барып чыкмас төсле тоелган иде ул. Безгә бит һәр сәгать саен, хәтта төнлә дә кунаклар килде. Тыңлаучылар да шушы вакыт дәвамында безнең белән булды. Башка редакцияләрдә эшләүчеләр җылы ашлар, чәйләр китерде. Шулай итә-итә, ерып чыктык без аны. Хәзер инде 60 сәгать тә куркытмый кебек (*көлә*). Ялгышмасам, рус телле радиоларның берсе нәкъ шундый рекорд куйды. Без исә аны да арттырырга тиеш булабыз. Бу ниятебезне яңа елга кадәр тормышка ашырырга насыйп булса ярар иде. Рекордлар китабына ук кереп булмас, әмма үзебезне сынап карыйсыбыз килә. Алып баручыларыбыз 40 сәгатькә түзәрме, 50гәме – күрербез. Насыйп булса, рекордын да куярбыз.

:: Белүемчә, «Күңел»дәге алып баручыларның күбесе – яшьләр. Үзләре киләләрме, сез чакырасызмы?

– Элеккеге состав алышынганнан соң, «Күңел»гә яшьләр килде. Заманасы да шуны таләп итә бит. Яшьләр һәрдаим килеп тора, кастингларны инде оештырмыйбыз да. «Сездә эшлисем килә», – дип киләләр. Аларның кызыксынуы танылу теләге белән бәйлеме, әллә күңел халәтләре шундыймы – анысын белмим. Әмма мондый теләк белдерүчеләрнең күп булуы, әлбәттә, сөендерә генә. Хәзерге вакытта «Күңел» радиосын 3 миллионлап кеше тыңлый. Элек күбесенчә өлкән яшьтәгеләр тыңласа, хәзер тыңлаучыларыбыз арасында яшьләрнең саны арта. Кыскасы, безнең «Күңел» елдан-ел яшәрә.

:: Чаллы белән Казан арасында шактый чакрымнар ята. Бу ике шәһәрнең тамашачылары, тыңлаучылары да бер-берсеннән шактый аерыла, диләр. Килешәсезме?

– Чаллы тамашачысы татар мәдәнияте үзәгеннән читтәрәк булгач, аның татар җырына, моңына сусавы көчле. Шуңа да алар татарча концертларны зарыгып көтеп ала, зал тутырып йөри, татар җырларын да йотлыгып тыңлый. Төп аерма шулдыр, миңа калса. Җырчылар да шулай ди.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

6+

ТАТАРСТАННЫҢ ИҢ ӨЛКӘН КЕШЕСЕ:

«БЕРКАЙЧАН ДАРУ ЭЧМӘДЕМ»

Зәйдә яшәүче Антонина Чижовага май аенда 107 яшь тулган. Бер гасырдан артык гомер юлын үткән әбекәй бүген дә сәламәтлегеннән зарланмый. Күзләре күрә, колагы ишетә, хәтере бик яхшы. Әле дә телевизор карый, ил-көн яңалыкларын күзәтә, сәясәт белән кызыксына икән. Кыскасы, бер белмәгәне юк. Әбекәйнең ничек яшәве, озын гомерлелек сере хакында без аның 85 яшьлек кызы Людмила Задера белән сөйләштек.

– Әнием Казахстанда туган. Алар гаиләдә өч бала була. Әтиләре Михаил тимер юл станциясендә эшли. Гаиләгә яшәү җиңел булмый. Алар тиф, холера чәчәк аткан чорга да эләгә. Әлеге авырулар аларны ятим итә. Тифтан савыга алмыйча, әтиләре үлеп китә, – дип сөйли Людмила Николаевна. – Күп тә үтми, илгә ачлык килә. Ашарларына өйдә бер кыерчык ипиләре булмый. Аларны 12 яшькәчә балаларны ашханәдә ашатулары һәм әтиләренең ипи пешерүче дусты коткара.

Чын дус була ул абзый. Сабыйлар яшәгән фатир янына килә дә шыпырт кына Антонинага исеме белән дәшә. Ә аннары киеме астына яшерелгән ипине балаларга бирә. Ул чакта Антонинаның әнисе нинди эш кушсалар, шуны эшли. Берәүләрнең иДәнен дә юа, самавырын да куеп тора, табын да кора. Сабыйларына ризык кына кайтсын! Еллар уза, балалар әкренләп аякка баса. Аларның өчесе дә әниләренә чиксез рәхмәтле була. 107 яшенә җиткән Антонина Михайловна бүген дә әнисен батыр хатын-кыз иде дип искә ала икән.

– Безнең әни 19 яшендә кияүгә чыга. Әтиебез Николай тегүче була. Башта остаханәдә эшли, аннан фабрика директоры итеп куялар. Алар бер-берләрен бик ярата. Мәхәббәтләрен тулыландырып, энем Вячеслав белән мин туганмын, – дип искә ала Людмила ханым. – Бөек Ватан сугышы безнең дә тормышның астын өскә китерә. Сугыш башланып, ике ай узгач, безнең әтине дә фронтка алалар. Күп тә үтми, аның үлем хәбәре килә. Миңа ул чакта бары тик 4 кенә яшь, энемә 3 тулган була. Әни 26 яшендә ике баласы белән тол калды. Бүтән кияүгә чыгам димәде ул. Безнең өчен яшәде.

Сугыш елларындагы авырлыкларны Антонина Чижова күпме еллар узса да хәтерли. Һәр кешегә бирелгән азык-төлек карточкасының ярдәме була. Ике балага бирелгән 300 грамм, әнисенә дигән 200 грамм, үзенә эләккән 400 грамм ипи аларны яшәтә. Ә бервакыт Людмила белән энесен бер солдат шикәр белән сыйлый. Алар беренче тапкыр баллы әйбер ашап карый. Шул шикәрнең тәме әле дә авызымда тора, ди Людмила ханым.

Антонина Михайловнаны ачы хәсрәттән балалары коткара. Алар, әнисе еласа, килеп, кулларын үбәләр икән. Сабыйлар да әтиләрен сагына. Кайтыр дип көтәләр. Антонина ханым да өметләнә. Хәтта сугыш тәмамлангач, вокзалга солдатлар каршы алырга бара. Янәсе, ире кайтмасмы?

Тик ул кайтмый.

– Өйдә ашарга бетсә, әни әтинең киемнәрен сата иде. Без ач булмасын өчен шулай эшләде ул. Ә бит алар әби белән икесе ач та кала иде, – ди Людмила ханым. – Әниебез Зәйгә 80 яшендә күченде. Ул чакта энем ГРЭС төзергә килгән иде. Өчебез дә Зәйне яраттык. Тик, кызганыч, энем моннан 10 ел элек вафат булды. Мин дә яшь түгел инде хәзер.

zainsk-inform.ru

Антонина Михайловна үзенең озын гомерле булуына шатлана. Апасы Серафима да 100 яшькә кадәр яшәгән.

– Беркайчан да кешеләр белән сүзгә килмәдем. Берәүне дә кимсетмәдем. Кешеләргә гел яхшылык кына эшләдем. Бер тамчы исерткеч эчемлек эчмәдем. Озын гомер сере шулдыр, – ди әбекәй.

Ә менә кызы аның шушы яшькә җитүен гадел булуыннан күрә. Тагын шунысы да бар: Антонина Михайловна гомерендә бер генә дару да эчмәгән. Авырганын сизсә, халык медицинасын кулланган.

– Нәрсә пешерсәк, шуны ашый. Ашлар ярата. Камыр ризыкларын үз итә. Нәрсә ашыйсы килсә, шуны алып торабыз. Кадер-хөрмәттә ул, – ди Людмила ханым. – Әниебез шушы яшендә дә үзе генә тора. Мин көнгә әллә ничә тапкыр янына барам. Тик төнгә калыйм дисәм, син монда йоклый алмыйсың, гырлыйм мин, дип куып кайтара. Исән генә булсын. Ничә яшьтә булсак та, әни кирәк бит әле!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6715 данә
Гомуми тираж – 15318 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 346

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+